**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервын формалаштырганда, әзерләгәндә һәм файдаланганда Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 25 декабрендәге ПУ-1270 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы кадрлар резервына яки дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестры «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Мәгълүмат системасы) алып барыла.»;

б) 10 пунктның беренче абзацында икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмә рәвештә анда вазыйфалар биләү өчен дәүләт хезмәткәрләре (гражданнар) дәүләт органы кадрлар резервына кертелә торган структур бүлекчә атамасы һәм дәүләт органы кадрлар резервына кертелә торган дәүләт хезмәткәрләре (гражданнар) ризалыгы белән алар шулай ук билгеләнә ала торган дәүләт хезмәте вазыйфаларының түбәнрәк вазыйфалар төркемнәре күрсәтелергә мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункты өстәргә:

«$10^1$. Дәүләт органының кадрлар резервына Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешнең 2 яки 3 пунктында яисә $59^1$ статьясындагы 2 яки 3 пунктта каралган дисциплинар җәза бирелгән дәүләт хезмәткәре кертелә алмый.»;

г) 11 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәткәре (граждан) дәүләт органы кадрлар резервына кертелү яисә аннан чыгарылу турындагы дәүләт органының хокукый акты күчермәсе тиешле дәүләт органы кадрлар хезмәте тарафыннан дәүләт хезмәткәренә (гражданга) әлеге акт чыгарылганнан соң 14 эш көне дәвамында җибәрелә (тапшырыла).»;

д) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Дәүләт органы хокукый акты кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә дәүләт органының кадрлар хезмәте аңа нигезләнеп дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестрына һәм дәүләт хезмәткәренең (гражданның) Мәгълүмат системасындагы шәхси карточкасына бу турыда тиешенчә язып куюэшен башкара.»;

е) түбәндәге эчтәлекле $16^1 – 16^3$ пунктлары өстәргә:

«$16^1$. Дәүләт хезмәткәре (граждан) аларны биләү өчен кадрлар резервына кертүгә конкурс игълан ителгән граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә квалификация таләпләренә, шулай ук дәүләт хезмәткәрләренә дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында куелган таләпләргә туры килмәгән очракта, аңа конкурста катнашу рөхсәт ителми.

$16^2$. Дәүләт хезмәткәре Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешнең 2 яки 3 пунктында яисә $59^1$ статьясының 2 яки 3 пунктында каралган дисциплинар җәзага тартылган булса, аңа конкурста катнашу рөхсәт ителми.

$16^3$. Дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәрләре (гражданнар) турындагы мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме; биләгән вазыйфасы; ул билгеләнергә мөмкин булган дәүләт хезмәте вазыйфалары төркеме; дәүләт органы кадрлар резервына кертелү датасы) дәүләт органы кадрлар резервына кертелү турындагы дәүләт органының хокукый акты кабул ителгән көннән җиде эш көне дәвамында әлеге органның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

ж) 19 пунктта «Департамент тарафыннан алынган» сүзләрен «Мәгълүмат системасына кертелгән» сүзләренә алмаштырырга;

з) 27 пунктның дүртенче абзацына «дәүләт хезмәтенең» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәтенең ул билгеләнә ала торган иң югары вазыйфалар төркеменең» дигән сүзләр өстәргә»;

и) 28 пунктның беренче абзацына «дәүләт органында дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфаларын» сүзләреннән соң «(республика башкарма хакимият органнары территориаль органнарында дәүләт хезмәте вазыйфаларыннан тыш) сүзләрен өстәргә»;

к) 29 пунктның беренче абзацына «дәүләт органында дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфасын» сүзләреннән соң «(республика башкарма хакимият органнары территориаль органнарында дәүләт хезмәте вазыйфаларыннан тыш) сүзләрен өстәргә»;

л) 32 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) аның дәүләт хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркеменә кергән дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләнүе, бу вазыйфага әлеге зат Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервыннан билгеләнергә мөмкин;»;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) дәүләт хезмәтенең әлеге зат билгеләнергә мөмкин булган иң югары вазыйфалар төркеменә кергән, биләүгә тәкъдим ителгән вакантлы дәүләт хезмәте вазыйфасыннан кабат баш тарту;»;

түбәндәге эчтәлекле «л» пунктчасы өстәргә:

«л) аны кылган өчен дәүләт хезмәткәре Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешнең 2 яки 3 пунктында яисә $59^1$ статьясының 2 яки 3 пунктында каралган дисциплинар җәзага тартылган дисциплинар тәртип бозу гамәле.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 16 август
№ ПУ-707